КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 18 июль г.Казань № 859

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2022 ел, 2 декабрь, 1276 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 20 март, 281 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аттракционнарның техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2023 ел, 18 февраль, 153 нче карары белән расланган Аттракционнарның техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин